Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 11

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Миңлебай авыл җирлеге
Миңлебай станциясендә гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 15 нче ноябрендә, 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Миңлебай станциясенең Ф.Кәрими, Сөләйманова, Җиңүнең 40 еллыгы, Вокзал урамнарында, Шоссе урамындагы №1- 20 йортларда, Урман урамындагы №1- 39 йортларда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай станциясе мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Вокзал урамы 23 нче йорт.

2. 2019 елның 15 нче ноябрендә, 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Миңлебай станциясенең Шоссе урамындагы №22 - 83 йортларда, Урман урамындагы №40-89 йортларда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай станциясе гомуми белем бирү мәктәбе бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Шоссе урамы, 46а йорты.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай станциясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Миңлебай станциясендә юлларга асфальт салу, сметалар тезү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай станциясендә сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Миңлебай станциясе, Шоссе урамы, 20а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) кененнән үз кеченә керә.

Миңлебай
авыл җирлеге башлыгы И.М. Рәхимов